ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ НОЯБРЬ * 2020 * КАЗАН

11



Сергей АНДРИАНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

ГЕЛ – КИРЕСЕ

– Элек балаларны
урамнан кертеп булмый иде,
хәзер куып чыгарып булмый.

– Элек алар илне тараттылар,
хәзер җыя алмыйлар.

– Элек алар КПССта иделәр,
хәзер "Единая Россия"да.

– Элек алар "Алла юк!" – дип йөрделәр,
хәзер мәчеттән чыкмыйлар.

– Элек түләмичә укып Кеше булдык,
хәзер түләп укып Хур булдык.

– Элек мәктәп иде – Интернационал,
хәзер – Полилингваль.

– Элек җитәкчеләрнең хезмәт хакы зур иде,
хәзер – хатыннарыныкы.

– Элек гел алга карый идек,
хәзер гел артка.

– Элек "Ур-ра" – дип кычкыралар иде,
хәзер – "Урла!"

– Элек төрмәгә утыра иде үтерүче,
хәзер гаепле – үлүче.

– Элек яшәгәнбез икән әле,
хәзер ник туганыңа үкенәсең.

– Элек куркыныч иде – Аждаһа,
хәзер инде – ЖКХа.

– Элек илне зурлыйлар иде,
хәзер талыйлар гына.

– Элек матбугат дүртенче власть иде,
хәзер ничәнче? Юк белүче.
Элек Ливар абый түрдә утыра иде,
хәзер дә шулай.

– Электән үк йөрдем булып Хәмзин,
Кытайлар килсә, әйтерләр, Кем – син?..
Менә хәзер гел киресе:
Киләчәккә – бушлык хисе...

ХӘМЗИН ТЕЛЕНДӘГЕ ӘЙТЕМНӘР

Киңәшчеләр күп хәзер –
Ахыр заман җитәдер?..

Хезмәт герое иде
Мактау тактасында.
Эләгәләр хәзер анда
Урлап мактасалар да.

Җырчылар ишәя –
Продюсерлар масая.



Игорь КИЙКО



ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Турыдан-туры әйтергә телим – башкалабызда юллар яхшырганнан-яхшыра. Һәрхәлдә, шәһәрнең төп трассалары кайчандыр авыз суыбызны агызып сөйләгән Европа автобанерыннан һич ким түгел – тигез асфальт, билге сызыклары, светофорлар, багана саен күзәтү камералары... Тагын шәһәр яны бистәләрендә дә тәртип урнаштырсалар, Рәсәйнең ике бәласе турындагы классикның сүзләре актуальлеген югалтыр иде...

В. ХАЛИТОВ

КАЗАН

– Әгәр бездә юллар белән барысы да тәртиптә икән, бу – ахмаклар юкка чыкты дигән сүз түгел әле! – диде Шомбай агабыз, укучының хатын укып чыккач.

ЯҢА ХӘБӘР

Башкаладан яңа хәбәр килде –
Чикләре юк безнең шатлыкның:
Дәүләт башлыклары карар кылган
Арттырырга санын халыкның.
Безгә нәрсә?..
Гомер буе ничек
Торган булсак, шулай торабыз.
Бала тудырырга вакыт җитми:
Үлмәскә дип дөнья куабыз...
Хатыннар да җиккән атлар кебек –
Ирләрдән ким икән кайсысы?
Булганнарын үстерергә кирәк –
Кайда монда бәби кайгысы...

Өстәгеләр салкын акыл белән,
Уйлап кына кыла гамәлен,
Халык үрчетүнең җаен белә,
Бала тудыруның әмәлен.
Өстәгеләр – алар бик булдыклы,
Пәйда булса кайсы төштә дә.
Фидакарьлек күрсәтәләр алар
Сүздә генә түгел, эштә дә...

...Әле уң як күршем сөйләп торды:
Тотынганнар алар, ди, дәүдән –
Шушы максат белән таза ирләр
Килеп төшкән, имеш, Мәскәүдән...

Ринат АБЗАЛОВ





ТУЙМАС КАЗНА КОРБАННАРЫ

Тәҗрибәле эшмәкәрләр арасында салымнан да начар нәрсә – салым түләрлек керемең булмау дигән гыйбарә йөри. Ә акчаң булганда, хөкүмәт кешеләрнең кесәсенә кулын тыгуның җаен таба белә: НДС, НДФЛ, транспорт һәм юл салымы, акцизлар, әле тагын үзмәшгульләр дигән нәрсә уйлап чыгардылар... Әгәр гади кеше акчалата ясак түләгәндә соңгы ыштанын салып бирергә мәҗбүр булса, эшмәкәр халкы түләү-түләмәү мәсьәләсенә киңрәк карый. Һәм моны аңларга да була. Чөнки акчаң күбрәк булган саен, аның белән аерылу кыенрак бит. Һәм керемнәре белән бүлешмәс өчен алар төрле хәйлә кора башлый. Кайчагында бу көлкеле хәлләргә барып җитә...

Берзаман бер эшкуар ханым салым идарәсенә үзәк өзгеч хат язган. Ходай хакы өчен, миннән салым алмагыз, дигән ул. Сәбәбен дә аңлаткан: имеш, ул эш өчен артыгын янып, бик каты башын бәргән һәм хәтерен җуйган. Ләкин бу тарих кырыс закон сакчыларының җанын эретмәгән, ә ханымга үз-үзен аямыйча тапкан акчасы белән бүлешергә туры килгән... Татарстан эшмәкәрләре мондый хатлар язмыйлар әле, ләкин керемнәрен яшерү өлкәсендә артта калмаска тырышалар. Мәсәлән, "Репродукт" җәмгыяте башлыгы бюджетка 9 миллион сум тиеш булган. Ләкин бизнесменның мондый зур акчаны дәүләтнең төпсез казнасына саласы килмәгән, һәм ул 10 миллион сумны сөйләшенеп куйган кешеләрнең счётларына күчергән. Бу гади хәйләне тиз ачканнар, хәзер элекке директорны акча урынына суд эскәмиясе көтә. "П. В. Дементьев исемендәге агрофирма" оешмасы директоры да шул ук такыр сукмактан китәргә булган. Аның яшереп калырга теләгән суммасы кимрәк булса да, җанына шулай ук кадерле булгандыр. Салымнар буенча бурычы булуын белсә дә, ул түләнәсе 3,8 миллионның 2,8 миллионын үзендә калдырган. Ләкин без капчыкны тишә бит – хокук сакчылары акчаны тапкан. Директор гаебен таныган, бурычын дәүләткә кайтарган... Ә менә «КазаньТрансЭкспедиция» компаниясенең директоры бу эшкә төптән әзерләнгән. Кирәкле исәп-хисаплар ясап һәм салымнарны түләү аның мәшәкатьле тормышына тынгылык өстәмәячәген аңлап, ул дәртләнеп керемнәрен саклап калу өстендә эшли башлаган. Ялган килешенүләрне һәм бухгалтерия документларын оста рәвештә әвеш-тәүеш китереп, директор әфәнде салым хезмәтен өч ел буе алдап йөрткән. Нәтиҗәдә, аның дәүләткә бурычы 81 миллион сумга җиткән. Һәм тир түгеп җыйган 72 миллионлык мал-мөлкәтне дәүләт кулына тапшырырга туры килгән, ә ул үзе хәзер суд карарын көтә.

Кызганыч, мондый мисаллар җитәрлек. Көн саен артып барган түләүләрдән нишләргә белмәгән бизнес, еш кына закон кысаларыннан чыгып булса да аларны кыскарту ысулларын эзли. Ә өстә утырган дәүләт әһелләре, бер-берсе белән ярыша-ярыша, туймас казнаны тулыландыруның яңа әмәлләрен таба тора. Төпсез фантазия ияләре Интернет һәм табигатьтә ясаган мәҗлесләр, күптән онытылган "баласызлык өчен", хәтта... офиста су эчкән өчен дә акча каерырга тәкъдим ясый. Яңа салымнар кертелүдән ризасызларга ясак саласы гына кала... Бер юаныч кала – бу саташуга тартым тәкъдимнәр хәзергә тормышка ашырылмый әле. Ә алдагысын вакыт күрсәтер. Бәлки, закон уйлап чыгаручылар салым йөгенең күтәрелмәс дәрәҗәгә җитү мөмкинлеген аңлап алырлар әле...

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр АЛЁШИН

Алексей МАМАЕВ





Василий АЛЕКСАНДРОВ



• • •

– Безнең фирма кагыйдәләре буенча, сез үзегезнең хезмәт хакыгызның күләмен беркемгә дә әйтергә тиеш түгел.

– Минем үземнең дә бу мәсьәләдә кимсенәсем килми иде.

• • •

– И Ходаем, нәрсә булды сиңа? Йөзеңә карарлык түгел – тырналып беткән, күз төпләрең шешеп чыккан... Әйдә, өеңә кайтарып куям!

– Син, нәрсә! Шуннан чыгып киләм дә инде...

• • •

– Картайган көнеңдә бер тамчы суны сиңа кем каптырыр?

– Соң, кулер сатып алыгыз да шуны караватыгыз янына куегыз!

• • •

– Нәрсә, Сания, балаларыңны авылга алып киттеңмени?

– Әйе шул. Әти-әни янына буш кул белән кайту әллә ничек...

• • •

Ике эт чирәмдә сөйләшә:

– Гаҗәп – этләр бит элек-электән борынчык-битлектә йөрделәр, ә кешеләр әле хәзер генә кия башлады, – ди берсе.

Икенчесе җавап бирә:

– Без бит әле космоска да аларга караганда алданрак очтык!

• • •

СССРда секс булмаган, ләкин һәр гаиләдә ике-өч бала туган. Хәзер секс бар. Әмма гаилә саен бер бала. Йомгаклап әйтсәк: димәк, балалар секстан тумый. Аларны ләкләк алып кайта...

• • •

– Кода! Син үз фирмаңны ачкансың икән. Бәлки мине эшкә алырсың?

– Әлбәттә! Тик кечкенә генә шартым бар – чит ил телне белү һәм компьютерда эшли белү кирәк.

– Ай-яй, җайлы котылдың миннән!

• • •

– Доктор, керәндә дәвалау сыйфатлары бармы?

– Әйе, әгәр дә аны бөтен нәрсәгә сылап барасыз икән, сезгә сизелерлек рәхәт булып китәчәк.

Абау!

ИДЕЛ ЯРЛАРЫНДА БАСЫП ТОРАМ...

«Средволгаводхоз» компаниясенең элеккеге директоры Фоат Мөхәммәтшинга хокук саклау органнарының күзе төшкән. Берничә ел элек ул Мамадышта Нократ елгасының ярларын ныгыту буенча 184 миллион сумлык эш кабул иткән, ә чынлыкта исә моңа бары тик 137 миллион тотылган булган. Берникадәр вакыттан шундый ук хәл Куйбышев сусаклагычы ярларында кабатланган. Бу очракта аерма инде 67 миллион тәшкил иткән. Бу акчаларның кем кесәсендә утырып калганын суд ачыклар. Ә Мөхәммәтшинга карата җинаять эше хезмәт вазыйфаларын файдаланып, зур күләмдә кеше милкен үзләштергән өчен кузгатылган.

КЫЙММӘТЛЕ ТЫРЫШЛЫК

Татарстандагы "Бурычсыз тормыш" ("Свобода от долгов") коллекторлык бюросы кирәгеннән артык бәйләнчеклек өчен җәзага тартылган. Берничә бурычлы кеше бюро хезмәткәрләренең берәзлексез аларның танышларын телефон сорап борчулары һәм бурыч күләме турында мәгълүматны ачуларына зарланган. Шикаятьләр игътибарсыз калмаган: "тырыш" коллекторларга 50 мең сум штраф түләргә туры килгән.

ПАСПОРТ БУЕНЧА УРЛАУ

Казан полицейскийлары электр самокатлары урлауны ачыклаганнар. Бер егет арендага 200 мең сумлык үзйөрешле җайланма алган, ләкин аларны кире кайтармаган. Хезмәт белән файдалану өчен шук егет паспортын калдырган булган, шуңа күрә Волжскида яшәүче 27 яшьлек каракны табу кыен булмаган. Ул кылган гөнаһысын таныган һәм урланган самокатларны ломбардка тапшыруы турында белдергән.

ЙОДРЫКЛЫ ФИКЕР АЛЫШУ

Чистайда ике юл инспекторы иртән хезмәт урынына бару алдыннан сугышып киткәннәр. Җәнҗалның сәбәбе – утырып барасы машинаның көпчәге тишек булуы. Хезмәттәшләр бу хәлдә кайсысының гаепле булуын ачыклый башлаган. Бераздан фикер алышу сугышуга күчкән. "Сугышчы"ларның берсе, теш казнасы сынып, хастаханәгә эләккән.







Рөстәм ЗАРИПОВ

ӨНЕММЕ, ТӨШЕММЕ?

Мин төш күрдем, имеш, бер киңәшче
Гади халык белән очраша,
Без авыз ачып тыңлыйбыз, ә ул
Киңәшләрен бушлай өләшә:
"Кеше булыйм дисәң, коерык болга,
Ялагайлан газиз түрәңә,
Биш – артына, биш алдына төшеп,
Иел, бөгел, булма бүрәнә...
Заманалар авыр, еллар ябык,
Шуңа күрә, зинһар, тартынма,
Хуҗаң тели икән, җебеп торма,
Үбеп ал битен дә, артын да.
Аңла, шунсыз кеше булып булмый!
Депутатлык төшми күкләрдән...
Чәчең белән себер баскан эзен,
Вакытыңны зая үткәрмә...
Талант, сәләттән кем файда күргән,
Белмәсәң дә ярый эш рәтен,
Әлләкемнәр булып була бүген,
Әзрәк җибәрсәләр күтәртеп...
Космос белән җитәкчелек итсәң,
Ракеталар төшәр, кадалып,
Әдәбият – сәнгать иярләсәң,
Талантсызлар йөрер ат алып...
Җитмешкәчә шулай яшәү кулай,
"Савытник" итәрләр аннары...
Айлы кичләр дәртләндерер гелән,
Алсуланып атар таңнарың...
Савытник дигән текә вазыйфа
Талиңкә тотуга ишарә,
Минем киңәшләрне тотмасагыз,
Тотып калачаксыз шишара...
Шул мәл татлы йокымны бүлдереп
Кесә телефоным шалтырый,
Түрәм шалтырата булып чыкты,
Нихәл итим, тезләр калтырый...


Валерий ТАРАСЕНКО

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

- Беренче сөюнең бөтен сихрилеге аның икенчесе булачагын белмәүдә.
- Олы яшьтәгеләр өчен яшьлек – иң зур кимчелек.
- Хатыннар иң акыллы ир белән дә уртак тел таба ала, ә ахмаклар белән – иң акыллылары гына.
- Хатыннар матур ирләргә түгел, ә чибәр хатынлы ирләргә игътибар итәләр.
- Хатын-кыз сөюнең мәгънәсен, ә ир кёше бәясен белә.



Михаил ЛАРИЧЕВ



Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

ГАЛИЯ ТҮТИ – ТАБИБТА...

Галия түти табибларга йөрергә яратмый иде. Нишләмәк кирәк, картлык үзенекен итә: хәтере дә кимеде. Йә күзлеген югалта, йә ачкычын. Кич җитсә, көндез ни ашаганын белми. Менә балалары бит табибка күренергә кушалар. Бәлки, берәр чарасын күрер.

Әйтүе җайлы ул, ә ничек язылырга соң аңа? Компьютердан эш итә алмый, бик рәхәт булыр иде дә югыйсә. Һәм әлеккечә – иртәгесен иртүк барып утырырга булды табиб кабинеты төбенә. Барса, анда инде аның кебекләр дәваханә ишеге каршында байтак җыелган иде. Менә, ниһаять, ишекләр ачылып китте, һәм алар талон бирә торган тишеккә ыргылды.

– Кызым, миңа да табибка талон бир әле, – дип, эчтә утыручы яшь кенә шәфкать туташына мөрәҗәгать итте ул.

– Әби җаным, кызганыч, якындагы көннәргә бернинди дә талоннар юк шул. Киләсе айга ярыймы бирсәм?

– Түзәрмен инде. Бир, әйдә. Аңарчы яшәп булса ярый да...

Галия түти, кадерле талонын тотып, өенә кайтып китте. Көткән вакыт акрын үтсә дә, менә килеп тә җитте. Ул табибка юл тотты. Коридордагы халык гадәттәгечә түгел, азрак иде. Чираты да тиз бара. Галия түти тыйнак кына ишек шакыды.

– Керегез! – дип мыгырдады эчтән берәү.

Керде. Өстәл артында, компьютерга текәлеп, табиб утыра иде.

– Нәрсәгә зарланасыз? – дип сорады ул.

– Менә, җаный, ни... мин...

– Йөрисез инде эч поштырып, бер файдасызга... Әгәр сездәйләрне шалт итеп, тиз генә дәвалый алсак, үзебез чирләр идекмени?

– Нәрсә, җаный, берәр җирең авыртамы әллә? – дип борчылып сорап куйды Галия түти.

– Менә йокысызлыктан интегәм. Бер ай чамасы күз йомганым юк. Дарулар да ярдәм итми.

– Җайлы гына дәвалап була бит аны, балакай! Бернинди дару кирәкми! Сөт җылыт та, бал белән төнгә каршы эч. Шундук йоклап китәсең.

– Ай рәхмәт, әбекәй. Минем әле башым да авырткалый. Шулай ук таблеткалар да булышмый.

– Кирәкми дарулар! Бик еш кофе эчәсеңме әллә?

– Әйе шул, кая куеп бетерим аларны? Китерәләр дә, китерәләр бит.

– Беләсеңме, нәрсә әйтәм мин сиңа? Ул кофеларны алар акция буенча алалар. Ә акция товарларның сыйфаты – ташка үлчим. Аларның зыяны күбрәк. Син үлән чәйләре эч, мәсәлән, иван-чәй. Үзебезнең болыннарда үскәннәрне – мәтрүшкаләләп. Бернинди баш авыртуың булмаячак.

– Ярар. Үзегезнең зарларыгыз нинди? Ни өчен миңа килдегез? – диде ул сәгатенә карап.

– Их, менә бәла, кабул итү вакыты чыккан икән бит. Мин әле сезнең белән үземнең хатынның сәламәтлеге турында киңәшмәкче идем. Килегез әле миңа икенче вакытта.

– Кайчан соң инде ул икенче тапкыр, балакай? Мин бит сиңа айлар буе эләгә алмадым.

– И әбекәй, бу кыен мәсьәлә түгел. Менә сиңа талон. Иртәгә килерсең.

Галия түти табибтан чыкты. Байтак уйга батып торды. Ни өчен килгән иде соң әле ул монда? Нинди сәбәп белән?

– Юкны бушка әйләндереп йөрим түгелме икән, аларның үзләренең дә мәшәкатьләре күп ләбаса. Ярар, ничек булса булыр, иртәгә тагын барырмын. Хатынын да дәваларга кирәк.











Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Олигархлар – бик сәер кешеләр. Үзләре байлыкта баткан, ә ярдәм сорамыйлар.

• • •

Җылылык бирү буенча "кайнар линия" эшли башлады. Хәзер һәр шалтыратучы "Ни өчен линия кайнар, ә батареялар юк?" – дип сорый ала.

• • •

– Ни өчен сез элекке эшегездән киттегез?

– Башта сез әйтегез әле: ни өчен элек сездә эшләгән хезмәткәр, сезнеке кебек әкәмәт яхшы урынны ташлап киткән?

• • •

Унбиш ел буе мин үземнең хезмәткәрләргә әйтә килдем: начальниклар – ахмаклар. Менә хәзер үзем начальник булдым. Инде мине башка уй борчый: элеккеге хуҗаларым шушы сарык көтүе белән ничек идарә итте икән дә, ничек берәүне дә бәреп үтермәде икән?

• • •

Зоопаркта:

– Әни! Миңа фил сатып ал әле!

– Ә без аңа нәрсә ашатырбыз?

– Бернәрсә дә! Менә бит монда язылган: "Ашату катгый тыела!"

• • •

Беренче сыйныф укучысы өендә ашап утыра:

– Әни, бик тәмле булды, рәхмәт. Ләкин миңа классташым Әлфия кызганыч. Аның беркайчан да тәмле ризык ашаганы юк.

– Нигә алай дисең?


– Аның әнисе безнең мәктәптә пешерүче булып эшли.

• • •

Күршеләр ачуымны чыгара. Бораулamыйлар да, музыка да кычкыртмыйлар, эчеп тавышланмыйлар да. Башка шундый уй килә: әйтерсең лә стенага колакларын терәп, безне тыңлыйлар!

• • •

Хатыным туган көнем белән котлады, бәхет һәм гаилә иминлеге теләде. Нәрсәгә булыр икән бу? Әллә ялгышып әйтүеме, әллә берәр нәрсә сизенде микән?



Рашат НИЗАМИ

СҮЗНЕ УЙНАТЫП БУЛА

Сүз димәктән, ул бит шундый нәрсә – авызыңнан бер очып чыктымы, кире кайтарып алырмын димә.

Илдар Юзеев белән дә шундыйрак хәл була бервакыт.

Аның эш бүлмәсендә кайнар гына сөйләшеп-бәхәсләшеп утырган төркемгә Марсель Галиев кушылып китә. Туктатырсың аны! Кайчагында бик ихлас, кайчакны усаллыгы белән дан алган егетләрнең берсе ул. Бу юлы, күрәсең, үзен тагын да усалрак тоткандыр, Илдар Юзеев, образлы әйтергә теләптер инде, "фашист" дип тамгалый моны.

Икенче көнне шагыйребез хафалана, әйткән сүзенең "ватерлиния" сызыгыннан узыбрак киткәнен чамалый. Андый чакта иң яхшысы – компромисс. Менә шуңа күрә дә ул, Марсельне очрату белән, үзенең кичәге сүзенә төзәтмә кертмәкче була.

– Марсель энекәш, кичә мин катырак әйтеп ташладым бугай. Ә чынлыкта мин сиңа неофашист дип әйтергә теләгән идем...

Икесе ике якка горур гына китеп баралар.

Әдәпле кеше буларак, Илдар Юзеевның әлеге мәсьәләгә барыбер уңышлы төстә нокта куясы килә. Җаен таба ул. Чираттагы очрашуларның берсендә Марсельгә болай дип җиффәрә:

– Мин бит сиңа теге көнне нибары антифашист дип әйтмәкче идем, хәтерлисеңме?..

Икесе дә рәхәтләнеп елмаялар.



БАШКА ЗАМАН...

Яшьлегеңдә күп тырышсаң,
Эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны
Бик тыныч һәм бик җиңел.

(Г. Тукай)

Яшьлектә күп тырыштык без,
Эшкә биреп чын күңел.
Барчасы хак сүз боларның,
Берсе дә ялган түгел.
Ләкин без көтмәгән якка
Алды тормыш юнәлеш.
Чит активка бара торды
Без башкарган һәрбер эш.
Кочып алды арттан килеп
Картаю дигәннәре.
Пенсия акчаларының
Чүп безгә тигәннәре!
Ләкин бюджет ямаганда
Һаман безгә карыйлар,
Карап-карап торалар да –
Һәм акыртып талыйлар!
Алар талау җаен белә:
Нигә ерак барасы? –
Яңа салым һәм тарифлар,
Пенсия реформасы...

...Хәзер барча үзгәрешләр
Начар якка тарта гел.
Нишләек соң, бездә хәзер
Тукай заманы түгел...

Бер карт абзый авызыннан
Ринат АБЗАЛОВ язып алды.









КЫЗЫКЛЫ ДӘРЕС

Төмән өлкәсенең Ишим шәһәренең 2 нче номерлы мәктәбенең тормыш иминлеге укытучылары "Террористлар басып алу вакытында үзеңне ничек тотарга" дигән темага гадәти булмаган дәрес үткәргәннәр. Сабакны тулысынча үзләштерелсен өчен, бишенче класс укучыларына терактның инсценировкасын ясаганнар. Кабинетка өлкән класста укучылар кергәннәр һәм балаларны куркыта башлаганнар. Укыту ысулларын прокуратура яраклы дип тапмаган. Педагогик иреклек өчен, мәктәп директорына штраф салганнар, ә ярдәмчесе һәм ОБЖ укытучысына шелтә белдергәннәр.

ТАГЫН БЕР ТИШЕК

Новоалтайск шәһәренең "җылылык челтәрләре" директорының машинасы үз организациясе каршысында җир астына төшеп киткән. Коммуналь авария нәтиҗәсендә, асфальтта тишек барлыкка килгән. Машинаны әйбәтләп чокырдан алганнар, ә интернетта моны кеше каргышы дип әшәке сүзләр язып тутырганнар. Тик алар иртә шатланган: зыян күрүченең организациясе гаепле булмаган – су үткәргеч тишелгән булган.

АТЛАР ӨЧЕН ШТРАФСТОЯНКА

Якутиядә хәзерге вакытта төп проблема булып караучысыз атлар тора. Шәһәрдә өч меңнән артык пар тояклылар бар икән һәм аларның күпчелеге урамда йөриләр. Алар чүп савытларыннан тукланалар, яшеллекне бозалар, машина йөртүчеләрне куркыталар. Ә ат асраучылар хайваннарны котәр өчен махсус урыннар булмавы, шәһәр читендә дачалар һәм торак йортлар булуына зарланалар. Мэрия атлар өчен җир бүлеп бирергә вәгъдә биргән, һәм шулай ук караучысыз атлар өчен ике штрафстоянка ачуы турында игълан иткән.

ДИНИ КАРАКЛАР

Нигериянең Бенуэ шәһәрендә чиркәүгә караклар кергән. Дин әһеле әйтүенчә, алар үзләрен тыныч тоткан һәм берөзлексез тәңре каршында гафу үтенгән. Алар чиркәүдән телефоннар, цифрлы җиһазларны, кием-салым, ашау, бөтен сәдаканы алып киткәннәр, тик дини булганнары өчен дин әһеле каракларга үпкәләмәгән. Ул аларның гөнаһларын кичерергә сүз биргән.

Вячеслав ШИЛОВ







Мирзаһит тормышыннан

ҖИҢЕЛ КАШЫК

Җәйге каникулларда Мирзаһитның улы Айнур үзе белән озын буйлы, бик таза егетне – курсташы Ришатны алып кайта.

– Ришат – спортсмен ул, – дип таныштыра улы, – тренажёрларда күп шөгыльләнә.

– Монысы бик шәп, – дип шатлана Мирзаһит. – Бүген иртүк торып печән чапкан идем, иртәгә бергәләшеп әйләндерергә барырбыз!

Икенче көнне иртән үзләре белән чәй, ипи, йомырка алып, кырга китәләр болар. Кичкә кадәр студентлар тирләп-пешеп эшлиләр. Караңгы төшкәндә генә кайтып керәләр.

Кичке ашны ашаганда арыган Ришат урындыгында көчкә утыра, хәтта кулындагы кашыгы да калтырап куйгалый.

– Бәлки, кашыкның җиңелрәген бирергәдер? – дип сорый Мирзаһит.

– Бөтенләй хәлсезләнгән шул, балакаем! – ди аның хатыны, һәм егетнең тимер кашыгын агачка алыштырып бирә.

– Бүгенгесе нәрсә әле аның, – дип дәвам итә Мирзаһит. – Менә иртәгә печәнне тояргә барабыз – сиңа, хатын, төшке ашка салам кашыклар әзерләп куярга туры килмәгәе!

Ришат бу хәбәрне ишеткәч, урындыгыннан чак егылып төшми...

ЯХШЫ ХӘБӘР

Берзаман Мирзаһит белән Вәли капка төбендә ял итеп утыралар икән. Каршыларында, кәпрәеп, әтәч йөри, үз җырларын җырлый-җырлый, тавыклар казына. Вәли ашыкмыйча гына гәзит актара.

– Карале, Мирзаһит – ди ул дустына, – ниләр язалар. Галимнәр ачыклаган: таулар торган урыннарыннан елына бер сантиметрга күчә икән! Ә материклар миллионлаган еллар эчендә берничә тапкыр кушылган һәм яңадан аерылган икән. Һәм бу хәрәкәт бүгенге көнгә кадәр дәвам итә! Ышанып та булмый: безнең авылның да меңләгән чакрымга күчеп куюы мөмкин бит.

– Яхшы хәбәр бу, – дип куйган Мирзаһит. – Болай булгач, бәлки, без дә чит илдә булып кайтырбыз? Гомер буе тавык саклап утырырга димәгән бит...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 16, 1984



Вячеслав БИБИШЕВ, «Чаян» № 6, 2004



Фәридә ХАҖИЕВА

ШУЛАЙ ЯШӘДЕМ

Татарстаныбыз, Казаныбыз шундый матур-бай булуда минем дә зур өлешем бар дип саныйм. Заманында Брежневка: "Казанда ит юк, әбиләр кичтән кибетләр янында колбасага чират алып, урамда куналар, ә эшләгән кеше нәрсә ашарга тиеш", – дип хат яздым.

Үзем өчен түгел – халык өчен яздым... Горбачев килгәч: макарон да, чәй дә, песок та, аракы да талонга бирелә башлады. "Рөхсәтсез, үзебез төзегән өйләрдә – кеше почмакларында пропискасыз яшәүчеләр ачтан үләргә тиешме?" – дип, Горбачевка хат яздым.

Авылга кунакка кайткач, укытучым керде, хәлләр белешкәч: "Фәридә, син язасың, яз әле безнең авыл күпере турында. Яз саен күперне ташу суы алып китә иде..." Үзем дә ул хакта уйлап утырам әле, "ЧАЯН"га язып бирәм, дидем. Күп тә үтмәде, күперне тимердән, ташу алып китмәслек итеп ясадылар... Шуннан улымны 18 яше дә тулмаган килеш армиягә алып киттеләр. Куркыныч группировка заманы, күпме яшьләрнең гомерләре өзелде. Өч айдан баланың хәлен белергә Шадринск шәһәренә бардык. Өч көн чәй дә эчә алмадык, краннан тозлы су ага, улым ябыккан, бөтен тәннәрен җәрәхәт баскан. Күкрәгемә башын куйды да: "Әни, исән килеш черим", – диде. Кайткач, Кремльгә хат җибәрдем: "Патша, малай тугач ат биргән, җир биргән, ә сез миңа нәрсә бирдегез, 20 ел эшләп фатир да ала алмыйм. Фатир сорагач, балаларыңны ятимнәр йортына бир, үзең тулай торакка күч!" – диделәр. Минем үземә терәк булсын өчен үстергән улымның бер тиен дә булышмаган ил каршында нинди бурычы булырга тиеш? Улымны кайтардылар. Менә хәзер, балалар тугач, акча түләгән булалар... Аны бит үстерергә дә кирәк әле. Көннәрдән бер көнне мунчаларга бәяләр күтәрелде... "Бу тузган торакларда яшәүчеләр ничек юынырга тиеш?" – дип, үзебезнең Госсоветка килдем. Фәндәс Сафиуллин: "Гаризагызны сессия вакытында коридорга эләрмен", – ди. Мин: "Хоть туалетка эл, тик эшләсен", – дидем. Маяковский урамында 25 кв. метрда җидәү яшәгәндә Язучылар союзында Шаһинур Мостафин миңа: "Син Путин белән бер көнне туган, хат язып җибәр, фатир бирмәсме", – диде. Чыннан да, хат юлладым. Җүләр дә инде үзем – шуңа ышанып торам бит. Тоттырдылар ди...

Татарстанның 100 еллыгына Хезмәт ветераны удостоверениесен аласым килде. 30 ел трамвай идарәсендә эшләп, шул исемне ала алмадым. Әйе, "Ударник Комтруда" ны бирделәр бирүен, тик хезмәт кенәгәсенә "ценный подарок" дип язылган. Ә мин ике айлык баламны иремә калдырып, төнге сәгать өчтә торып, трамвай йөртергә чаптым, 30 ел бер прогулсыз, нарушениесез эшләдем. Быел миңа 70 яшь тула, Аллаһ боерса, Казанга кайтканыма – 50 ел. "Без сине чакырмадык – кайдан килсәң, шунда кит!" – дип кимсетүләренә җавап итеп шигырь яздым.

Кош тырнагында очкан балыкның
Җан әрнүен кем аңлый икән?
Әллә ул да үзен зәңгәр күктә
Канатландым, дип алдый микән?!

Эльвира ДЫШАЕВА



ИГЪТИБАР!

ТАТ МЕДИА

Кышкы язылу өчен кар көри торган машина, кухня техникасы һәм гаджетлар от!

Бүләкләр 2021 елның 12 февралендә уйнатылачак



1 язып — 2020 елның 25 декабренә кадәр ТАТМЕДИА АҖнең бер газета һәм бер журналына язып (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от — Язылган өчен тостер, чәйнек, смартфон яки планшет от. Төп бүләк — кар көри торган машина!



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 19.10.20 — 20.03.20 кадәр уздырыла. Гаризалар 30.01.2021 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ, Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

Алмаз ХӘМЗИН

Бер нәрсә үзгәрми...

Кызык та инде безнең тормыш бу илдә. Язмыш дисәң дә була... Революциягә хәтле кешеләрне изү җәмгыяте булган, дибез бит инде гомер буе. Феодализм, капитализм... Аңа хәтле дә рәхәт яшәмәгәндер ярлы халык. Бертуктаусыз сугышлар... Байлар, ярлылар... Тарихтан Радищевларны беләбез, Некрасовларны, Пушкин, Лермонтовларны, декабристларны, Белинский, Чернышевскийларны, Герценнарны – күп алар. Безгә бу язучыларны пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәреп өйрәттеләр. Яхшы җәмгыять төзү өчен патшаны үтерергә йөрүче "народоволец"ларны да без геройлар дип белә идек. Ул вакыттагы һәр язучы диярлек йә сөргенгә сөрелгән яисә төрмәдә утырган. Патшага алар дошман, ә безгә – правдолюб! Ленин да террорист, Тукай да ышанычсыз... Аннан соң социализм китә. Җәмгыятебезгә Сталин баш. Әлеге генә сөенә-сөенә бергәләп революция ясап йөргән, ялкынланып яңа җәмгыять төзүгә керешкән язучыларыбыз, "халык дошманы"на әверелеп, патша вакытындагылар кебек сөргенгә озатылалар һәм төрмәгә ябылалар. Боларның да фикер йөртүләре генсекныкы кебек түгел икән.

Халыкта мондый мәзәк бар:

Пушкин Сталинга килгән. Сталин моннан сорый:

– Нәрсәгә бик зарланасыз? – дип.

– Яшәргә фатирым юк, иптәш Сталин, – ди.

Сталин телефонны ала да:

– Моссовет? Иптәш Бобровников? Минем янда иптәш Пушкин утыра. Иртәгә үк аның Мәскәүдә иң яхшы фатиры булсын! Тагын нәрсә кирәк, иптәш Пушкин?

– Минем әсәрләрне бастырмыйлар, иптәш Сталин.

Сталин яңадан трубканы ала.

– Язучылар союзы? Монда миңа иптәш Пушкин килгән. Иртәгедән аның әсәрләрен иң күп тираж белән бастыра башлагыз!

Пушкин рәхмәтен әйтеп китә.

Сталин тагын трубканы ала да:

– Иптәш Дантес? Иптәш Пушкин чыгып китте!..

Бездә хәзер хәлләр ничегрәк дип уйлыйсыз? Дантеслары бар түгелме соң?



ҮПКӘЛЕ КЫСАНЛЫК

Кадерле Чаян! Республикабызда милли белем бирү темасы бик катлаулы проблемага әйләнде. Телгә кагылышлы булган мәсьәләләрне чишү өчен хәтта комиссия дә төзеделәр. Җитди адымнар белән тиз хәл итү кирәк дип, Тукай телендә сөйләшергә теләмәгән министрларны атадылар. Шул ук вакытта ике дистәдән артык районда татар мәктәпләре юк икән...

Идел буе районында андый бердәнбер мәктәп бар. Татар телендә укыта һәм 20 елдан артык эшләп килүче 18 нче гимназия. Ул – элеккеге балалар бакчасы бинасында урнашкан һәм үз бинасы беркайчан булмаган мәктәп. Әлбәттә, уку-укыту процессы өчен бу мәйдан гына җитми. Башлангыч белем бирү гимназиядә булса, 5 нче сыйныфтан алып 11 нче сыйныфка кадәр балалар өчен 45 нче мәктәптән урын арендага алына икән.

Гимназия ашханәсе бик тыгыз графикта эшли. Укучылар 15 агымга бүленгән. Физкультура дәресләре өчен спортзал да бик зур түгел. 35 кв. метр иркенләп хәрәкәтләнерлек түгел. Дүрт катлы өстәмә гимназия бинасының проекты әзер. Ул шул бинага кушылып төзелергә тиешле. Узган ел бу проектка экспертиза да үткәрелде, ләкин аның тормышка ашырылуы гына зур сорау астында. Төзелешкә акча юк, кысан биналарда тагын күпме азапланасы буласын әлегә укучылар да, укытучылар да, әти-әни дә, түрәләр дә белми...

Шунысы гаҗәеп, кысан булса да уку бик көчле дәрәҗәдә бара. Дистәләгән медалистлар гына чыгарыла ел саен. Шуңа да әлеге гимназиядә белем алырга теләүчеләр бик күп, аларны сыйдырып кына булмый...

18 нче гимназия укучыларының әти-әниләре.

КАЗАН

Виктор ФЁДОРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Ринат АБЗАЛОВ





Көн саен иртән редакция коридорында аның йомшак адымнары һәм салмак тавышы ишетелә иде. Маннур абый "Чаянга" шулай, эшкә йөргән кебек йөрде. Кулында калын портфель, портфелендә – яңа шигырьләр. Туксан яше күптән тулып китүгә карамастан, ул соңгы көннәренә кадәр редакция сукмагын таптады.

Маннур Саттаров – бөтен гомерен юмор һәм сатирага багышлаган кеше. Бөек Ватан сугышын үтеп, Казан педагогика институтын тәмамлаганнан соң укытучы, Язучылар клубы мөдире булып эшли. Аннан соң иҗат эшенә чума. Алтмыш ел чамасы аның әсәрләре төрле газета-журналларда басылып тора, ә 1982 елда нәшриятта "Мылтыклы шүрәле" дип исемләнгән җыентыгы дөнья күрә.

..."Язучылар берлегенә алмадылар, артык карт дип әйттеләр", – дип шаярта иде Маннур абый. Тик аңа да карамастан, берлекнең ул чактагы җитәкчеләреннән озаграк яшәп, соңгы сулышына кадәр безне шаян шигырьләре белән шатландырып торды.

Сатирик язучы Маннур Саттаровның 100 ел тулу хөрмәтенә укучыларыбызга аның иҗатына багышланган сәхифә тәкъдим итәбез.

ӘЙ НУЖАЛАР, НУЖАЛАР...

Әй нужалар, нужалар,
Безнең баштан узалар.
Нужалардан коткармакчы
Һәр сайланган хуҗалар.

Сары, сары, сап-сары
Сары чәчәк саплары.
Быел тагын күтәрелде
Барча түләү хаклары:

Киловаттка, литрга,
Һәр квадрат метрга.
Бәяләр артты күпкә
Өйләрдән чыккан чүпкә –

Чәчелгәнен урамга
Искән җилләр куганга,
Түшәм аша үткән сулар
Баскычларны юганга.

Хак өстәлде лифткә –
Көйле-көйсез бишеккә,
Куелмаган агу өчен
Күсе тишкән тишеккә,

Ясалмаган капремонтка
Йорт салынган заманнан –
Һәммәсе дә исәпләнгән,
Компьютердан саналган!

Калган фәкать исемлекне
Алфавитка көйлисе,
"А" дан башлап, "Я"га кадәр
Барын да без түлисе!

Әй нужалар, нужалар,
Безнең баштан узалар.
Шаккаттыра янә безне
Без сайлаган хуҗалар!

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР

Ишегалдым ак балчык,
Ак балчыктан атлап чык.
Кыскартыласың килмәсә,
Башлыгыңны мактап чык.

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз.
Берсен сеңлем дип әйтегез,
Икәү булса ярыгыз.

Интим хезмәт күрсәтүне
Уртак түшәк дип аңла.
Ирең белән киңәшмичә
Эшкә кермә син анда.

Кулымдагы йөзегемнең
Таныйм алмыйм исемен.
Пассажирларны сөймәсәң,
Таш ташырга куч, энем!

Җитми дисең акчабыз,
Бар бит әле бакчагыз.
Телефон да куйдырырсыз,
Бакчагызны сатсагыз.

Ай яктысы якты диеп,
Ташка басып су алма.
Салып куйсаң, өеңә кайт,
Нәшриятта чуалма!

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Экраннан киңәш алыгыз,
Кавык булса кайгыгыз.

Су буйларын тал алган,
Тамырлары таралган.
Ут-су хакын күтәрмәгез,
Без җитәрлек талангaн!

ЯРЫМ МИНЕ ТАШЛАДЫ

Бер егет авызыннан

Сөйгән ярым сөйкемле,
Җәннәт кошы шикелле,
Буе зифа тал кебек,
Иреннәре бал кебек,

Туган айдай кашлары,
Ләкин мине ташлады,
Җирән диеп чәчемне,
Утызда дип яшемне.

Китте...сиксән яшьлеккә,
Пенсиясе шәплеккә.
Карты – Хезмәт Батыры,
Үлсә, кала фатиры...

"БИШ"КӘ БИРГӘН

Төнге сәгать уникедә
Кердем ишегем ачып.
Йокы булмәбездә ят ир,
Маташмый хәтта качып!

Чибәрем әйтә: "Таныш бул,
Бу – укытучым минем.
Имтихан алуын сорап,
Өйгә чакырган идем".

Сузды миңа зачёткасын,
"Отлично" бит бәясе!
Юлдан кайтып, яман уйлар
Уйлама син, янәсе.

Яман уйлар уйлау кая,
Шатлыгым сыймый эчкә!
Кинәт биеп җибәрүдән
Тыелып калдым көчкә!..

Кайбер хатыннар болай да
Сөйдертә бүтән ирдән.
Арзанаймаган минеке –
Маладис, "биш" кә биргән!..

МИНЕМ ЯРЫМ

Минем ярым итче Барый,
Барый булуы ярый.
Итче булгач ярап булмый:
Симез кызларга карый!



Дамир МОРТАЗИН

Кирәклектә – бәрәкәт...

Бар иде бит һаваланып, күккә чөелеп, чынга ашмас хыялларга уралып йөргән чаклар. Мәнә шундый хисләргә чумып, әллә кем булырдай дәрәҗәләргә ирешердәй кәперәюләр. Тоттым да республикабыздагы үзем теләгән бер химзаводка комсомол юлламасы алып, яңа тормышка аяк басарга киттем. Вокзалда, көтмәгәндә, классташым Сабир очрады. Укыганда ул безнең староста да, утаманыбыз да иде.

– Химзаводка, дисең инде, – дип башлады ул үзенең сүзен миңа теләктәш рәвештә. – Ә менә мин язучылыкка керештем бит әле. Беләсеңме, аларның гонорары нихәтле? Әл-лә-лә... Мин инде бер роман яза да башладым. "Туган җирем..." Хәзер шуны язар өчен ашыгам...

Берничә елдан соң теге Ставрополь комбайнчысы – үзгәртеп коруны котыртучыдан ил рухы күтәрелеш алган чакта, янадан Сабир белән очраштым.

– Син хәзер кайда? – диде ул кызыксынып. – Илдә үзгәрешләр һәм яңа омтылышлар, ә син һаман химияләнүдәме! Мин менә публицистика белән мәшгуль. Бүгенге көндә журналистлар – заман геройлары, чит илләрдә дә шулай... Тоталитаризмны, сталинизмны тетеп салабыз, ленин идеалларына башка караш...

– Ә романың язылды мы соң? – дип әйтеп куйдым мин бер дә килешмәгәндә.

– Вакыты ул түгел, – дигәндәй кырт кисте Сабир. – Соңрак...

Сөйләшү шулай булды. Тиздән болтун комбайнчыны исерек Урал тумышлы адәмнең хәйләкәр өеме алыштырды. Бераздан Казанга эшем буенча командировкага килгәч, мин тагын Сабир белән күрештем.

– О-о, безнең химик! – дип тәрттеребрәк эндәште ул бу юлы. – Мин менә сәясәткә багышларга булдым әле үземне. Хәзер депутат – "Безнең йорт" партиясе тарафыннан. Заманы шундый – читтә калырга ярамый. Менә әле сайлау алды митингына ашыгам...

– Романың ничек соң, романың? – дигән соравым һавада эленеп калды. Ул нәрсәдер әйтте бугай, ишетеп бетермәдем...

Шуннан соң берничә ел узды. Ил буйлап Мамай узгандай, шок терапиясе һәм приватизация үтте. Безнең завод та кемнәрнеңдер кулына күчте. Шундый тынгысыз көннәрнең берсендә телефон шалтырады.

– Алё! Бу мин әле – Сабир, ничек анда сезнең приватизация үтә? Химзаводыгызның акцияләре кем кулында?

– Каян белим, – мин әйтәм, – Барысы да тирән сер белән коллективтан башка эшләнә.

– Ә нигә аны сорыйсың әле? – дип гаҗәпләндем мин.

– Син, нәрсә, айдан егылып төштең мәллә?.. Хәзер бит дөнья тәгәрмәчен бизнесменнар һәм булдыклы менеджерлар әйләндерә. Алар кулында киләчәк... Мин бизнес белән шөгыльләнәчәкмен... Менә хәзер шуны өйрәнәм, анализлыйм...

"Их, Сабир, – дип уйлап куйдым мин. – Бу болганчык нәрсаләргә кереп бата күрмә, үзеңнең романыңны гына язып утыр, башың исән калыр, ичмаса..."

Ләкин үзенә уңышлар һәм күп акчалар гына теләп калдым...

Әлләниләр кыланып бетелгән туксанынчы елларда исән калып, аннан соңгы күтәрелеш һәм түбән тәгәрәүләрне кичереп, мин үземнең гомеремне багышлаган заводымнан, зарарлы эштә эшләп, күптән түгел генә пенсиягә чыктым. Вакытым бар: ял көннәренә туры китереп, балалар янына Казанга киттем. Кирәк бит, шунда каяндыр каршыма Сабир килеп чыкты. Бу юлы ул беркая да ашыкмый иде бугай. Сыра эчәргә дип, бер барга кердек.

– Синнән шуны сорыйсым килә, – дип башладым сүземне. – Ничек романың, язылдымы? Исеме "Туган җирем"ме әле?

– Язып бетерә алмадым мин аны, – диде ул, яшермичә. – Барыбер аны әдәбият генераллары үткәрмәсләр иде югарыга. Аларга кирәкми бит минем кебек көндәшләр...

– Син публицистмы? – дип сорадым мин.

– Анда үз мафияләре. Ул валюта тагарагына үтеп кереп булмый...

– Ә сәясәт, бизнес?

– Син бигрәк инде, бала-чага кебек... Минем шәһәрдәге туган-тумачам белән сәясәт һәм бизнеска үтеп кереп буламыни? Анда инде йөз елга алдан бөтенесе язылган! Ләкин мин әле сыгылып төшмим. Хәзер, беләсеңме, кемнәр кирәк? Экологлар һәм хокук сагында торучылар. Аларга бөтен өмет...

Сабир үзенең сырасын чөмереп бетерде дә:

– Мин, йөгерим әле, эш муеннан. Хокук саклаучылар семинарына соңга калам, аннан соң экологлар мәҗлесенә... Кирәклектән коры калмау әһәмияткә ия! Ярый, химзаводчы, очрашканга кадәр...





САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1900) ноябрь 2020

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 3.11.2020 ел.
Тираж – 1931 Заказ А-2856

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!





1. Таҗлы вирусның беренче билгесе?

2. Кеше кайчан олыгая?

3. Ни өчен уртанчы звено башлыгы булып урнашырга авыр?

4. Англия – чәй куллану буенча бары тик икенче урында гына. Кем беренче?

5. Чын патриотның нәрсәсе булырга тиеш?

6. Ришвәтчелек белән ничек көрәшергә була?

7. Безнең кешеләр тик бер канунны бозудан куркалар. Кайсысын?

ҖАВАПЛАР

1. Оекбашларның исен тоймыйсың. 2. Иң йомшак уенчыкның диван икәнен аңлагач. 3. Чөнки өстәгеләр дә һәм синнән түбәндәгеләр дә – ахмаклар. 4. Бухгалтерия. 5. Баласы – Англиядә, счётлары – Швейцариядә, вилласы – Зәңгәр диңгез буенда, эш урыны – Ватанында. 6. Берничек тә. Бездә бит хәтта конвертларны да кәгазь акча кинлегендә ясыйлар. 7. Буш шешәне өстәлгә куярга ярамаганны.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 10 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – «СИПКЕЛЛЕ ДИМИЛӘР МИНЕ»

Беренче булып
дөрес җавап җибәрделәр:
Г. ХАННАНОВ (Томск өлкәсе, Вавиловка ав.),
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Ф. ГАБДРАХМАНОВ (Сарман р-ны, Боламык ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Вавиловкадан
Гаскәр ХАННАНОВ!


Ринат АБЗАЛОВ төзеде

Илдар НӘФИЕВ









Быел Казан сәнгать училищесы оешуга 125 ел тулды. Бу уку йортын тәмамлаган рәссамнар арасында шаян графикада эшләүчеләр дә аз түгел. Шундыйларның берсе – рәссам-график, китап бизәүче, дизайнер Илдар Нәфиев. Әмма ул укучы халык арасында иң шәп "Чаян" карикатурачыларның берсе буларак билгеле. Илдарның рәсемнәре инде егерме ел чамасы журнал битләрен бизәп тора, ә аның кабатланмас стиле укучыларның игътибарын җәлеп итә.

4612750670080